ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2023 г. Заинск № 124

**2022-2043 елларга Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программага үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексын, “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 72 номерлы карары белән расланган 2022-2043 елларга Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программада катнашучы торак милекчеләре ширкәтләре, идарәче компанияләр исемлеге

Әлеге Программаны гамәлгә ашыруда Зәй муниципаль районының түбәндәге торак милекчеләре ширкәтләре, идарәче компанияләре катнаша:

«Зәй шәһәренең ТКХ ИК» ҖЧҖ, «Доверие» ТМШ, «17 подъезд» ТМШ, «Тугыз катлы йорт» ТМШ, «Иске Зәй» ТМШ, «Нефтьче» ТМШ, «Төзүче» ТМШ.

2. Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң законлы көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Н. Кулагина
8(85558) 07-08-18